**Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы муниципаль бюджет гомумбелем учреждениесе «Мамадыш шәһәре дүртенче санлы урта гомумбелем мәктәбе»**

| | | |
|---|---|---|
| Каралды<br>Методик берләшмә җитәкчесе<br>_________Шакирзянова Д.Ф.<br>Беркетмә №1<br>26 август 2021 ел. | Килешенде<br>Укытуэшләре буенча директор<br>урынбасары _________Габдрахманова З.М.<br>27 август 2021ел | Расланды<br>Мәктәп директоры<br>_________Ханафеев И.М.<br>Боерык № 110 27 август 2021ел |

**Югары категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы**
**Шакирҗанова Диләрә Фазылҗан кызының 8нче а сыйныфы өчен**
**“Кызыклы грамматика“түгәрәге буенча**
**эш программасы**
**Тормышка ашыру вакыты: 1ел**

Педагогик киңәшмә утырышында каралды

Беркетмә №1 26 август 2021 ел

## Аңлатма язуы

**Шәхескә кагылышлы нәтиҗә:**

• Татар халкының милли-мәдәни кыйммәтләренең берсе буларак татар телен аңлау; шәхеснең интеллектуаль, иҗади сәләтләрен һәм әхлак сыйфатларын үстерүдә туган телнең мөһим ролен, мәктәптә белем алу процессында ана теленең әһәмиятен аңлау.

• Татар теленең эстетик кыйммәтен аңлау; туган телгә карата хөрмәт, аның белән горурлану; милли мәдәният күренеше буларак татар теленең чисталыгын саклау ихтыяҗы; сөйләм культурасында үзүсешкә омтылу;

• Сөйләшү процессында фикер һәм хисләрне иркен белдерү өчен сүзлек запасының һәм үзләштерелгән грамматик чараларның җитәрлек күләмдә булуы.

**Метапредмет нәтиҗәләр:**

• сөйләмнең барлык төрләренә ия булу:

• телдән сөйләшүне һәм язма хәбәрләрне тиешенчә аңлау;

• укуның барлык төрләренә ия булу;

• төрле стиль һәм жанрдагы текстларны тыңлап тиешенчә кабул итү;

• мәгълүматны төрле чыганаклардан, шул исәптән массакүләм мәгълүмат чараларыннан, уку-укыту процессы өчен дип әзерләнгән компакт-дисклардан, Интернет ресурсларыннан таба алу, төрле сүзлекләрдән, әдәбияттан файдалана белү.

• мәгълүматны сайлап алу һәм билгеле бер темаларга аеру, системалаштыру алымнарына ия булу;

• сөйләм текстларын эчтәлек, стилистик үзенчәлекләр һәм кулланылган тел берәмлекләре буенча чагыштыра һәм тәңгәлләштерә белү;

• алда торган шәхси һәм коллектив уку эшчәнлегенең максатларын, эш-гамәлләр эзлеклелеген, шулай ук ирешелгән нәтиҗәләрне билгели белү һәм аларны телдән, язма формада тиешенчә тәгъбир итү;

• төрле катлаулылыктагы сөйләмә һәм язма текстларны сөйләп бирә белү;

• төп фикер, адресат һәм аралашу ситуациясен исәпкә алып, төрле типтагы, төрле стильдәге һәм жанрдагы сөйләмә һәм язма текстлар төзү;

• үз фикереңне телдән һәм язма формада иркен һәм дөрес итеп тәкъдим итү;

• монолог һәм диалогның бөтен төрләрен дә үзләштерү;

• сөйләм практикасында хәзерге әдәби татар теленең төп орфоэпик, лексик, грамматик, стилистик нормаларын саклау; язма формада аралашу вакытында төп орфографик кагыйдләрне һәм пунктуация таләпләрен үтәү;

• сөйләм этикетын саклап, телдән аралашуда катанаша алу сәләте;

• үз сөйләмеңне эчтәлек һәм тел бизәкләре ягыннан бәяләү; грамматик һәм сөйләм хаталарын, төгәлсезлекләр табу һәм аларны төзәтү; үзең төзегән текстларны төзәтә һәм камилләштерә белү;

• яшьтәшләрең каршында зур булмаган хәбәр һәм докладлар белән чыгыш ясый алу;

• алган белем-күнекмәләрне көндәлек тормышта кулана һәм башка фәннәрдән белем алганда туган телдән файдалана белү, алган белемнәрне фәнара дәрәҗәдә файдалану (чит тел, әдәбият дәресләре һ.б.);

• Сөйләшү, нинди дә булса биремне бергәләшеп үтәү, бәхәс һәм тикшерүләрдә катнашу вакытында әйләнә-тирәдәгеләр белән максатчан рәвештә коммуникатив бәйләнешкә керү; формаль һәм формаль булмаган шәхесара һәм мәдәниятара аралашуның милли-мәдәни нормаларын үзләштерү.

**Предмет нәтиҗәләре:**

• телнең төп функцияләре турында, Татарстан Республикасының дәүләт теле һәм татар халкының милли теле буларак татар теленең әһәмияте турында, тел һәм мәдәният арасындагы бәйләнеш, кеше һәм җәмгыять тормышында туган телнең әһәмияте турында күзаллау;

• туган телнең гуманитар фәннәр системасындагы урынын һәм гомумән белем бирү өлкәсендәге әһәмиятен аңлау;

• туган тел турындагы фәнни белемнәрнең нигезен үзләштерү; аның баскычлары һәм берәмлекләре арасындагы бәйләнешне аңлау;

• лингвистиканың төп төшенчәләрен үзләштерү: лингвистика һәм аның төп бүлекләре; тел һәм сөйләм, аралашу, телдән һәм язмача аралашу; монолог, диалог һәм аларның төрләре; телдән аралашу ситуациясе; сөйләм теле, фәнни, публицистик, рәсми стильләр, әдәби тел; фәнни, публицистик һәм рәсми эш кәгазьләре жанрлары;

• сөйләмнең функциональ-мәгънәви төрләре (хикәяләү, сурәтләү, фикерләү); текст, текст төрләре; телнең төп берәмлекләре, аларның билгеләре һәм сөйләмдә куллану үзенчәлекләре;

• татар теле лексикасы һәм фразеологиясенең төп стилистик чыганакларын, әдәби татар теленең төп нормаларын (орфоэпик, орфографик, пунктуацион), сөйләм этикасы нормаларын үзләштерү; аларны язма һәм телдән сөйләм вакытында куллану;

• телнең төп берәмлекләрен, грамматик категорияләрен тану һәм анализлау, сөйләм ситуацияләре вакытында тел берәмлекләрен урынлы куллану;

• сүзгә төрле төрдәге анализлар ясау (фонетик, морфемик, сүзьясалыш, лексик, морфологик), сүзтезмә һәм җөмләгә синтаксик анализ; аңа төп билгеләре һәм структурасы, телнең билгеле бер функциональ төрләргә каравы, тел бизәкләрен кулланыуы, телнең тәэсирлелек чараларыннан файдалануы ягыннан күп аспектлы анализ;

• лексик һәм грамматик синонимиянең коммуникатив-эстетик мөмкинлекләрен аңлау һәм аларны үзеңнең сөйләмеңдә файдалану;

• Татар теленең эстетик функциясен аңлау, әдәби әсәр текстларын анализлау вакытында сөйләмнең эстетик якларын бәяләү сәләте.

**Түгәрәкнең кыскача эчтәлеге.** Түгәрәктәтүгәрәк курсының эчтәлеге белән танышу, дәфтәрләр башлау.

**Күренекле галимнәр.** Күренекле галимнәрнең иҗаты тормыш юлы турында дәфтәрләргә язу.

**Татар һәм рус телләрен чагыштырып өйрәнү**Түгәрәктә татар һәм рус телләрен чагыштырып өйрәнүнең кыскача тарихы белән танышу, сүзләрне дәфтәрләргә язу.

**Интонация.** Интонация турында кагыйдәләрне язу, интонация белән укырга өйрәнү. **Фонетика патшалыгына сәяхәт.** Фонетика турында кагыйдәләр белән танышу, өйрәнү.

**Фонетика**. Сүзлргә транскрипция ясарга өйрәнү.

**Графика.** Кагыйдәләрне язып алу,кызыклы күнегүләр эшләү.Текст белән танышу, сорауларга кыскача җавап бирү.

**Лексика.** Кагыйдәләрне дәфтәргә язу һәм өйрәнү. Фразеологизмнарны тәрҗемә итү, күнегүләр эшләү.

Берүк мәгънәле сүзләр белән танышу, алар белән җөмләләр төзү.  Күп мәгънәле сүзләр белән танышу, алар белән җөмләләр төзү .

**Җөмлә.** Сорау, өндәү, төйгылы җөмләләр язу. Кагыйдәләрне өйрәнү. Күнегүләр эшләү.

**Тел турында мәкальләр һәм әйтемнәр.** Тел турында мәкальләр һәм әйтемнәрне өйрәнү, дәфтәргә язып алу.

**Татар халык авыз иҗаты.** Татар халык авыз иҗаты белән танышу.  Әкиятләр уку, табышмаклар,җырлар өйрәнү, эчтәлекләрен сөйләү.

**Казан башкалам.**Татарстаныбыз башкаласы Казан шәһәренең тарихын өйрәнү, аңа  багышланган шигырьләр белән танышу**.**

**Татар халык ашлары.** Татар халык ашлары белән танышу. КВН уздыру. Җиңгән төркемне бүләкләү.Кроссвордлар төзү һәм чишү.

**Тел дигән дәрья бар...**Туган телебез турында мәкальләр белән танышу**,** дәфтәрләргә язу.

**Милли бәйрәмнәр.** Түгәрәктә  татар халкының милли бәйрәмнәре белән танышу.”Сөмбелә”, “Сабантуй”, “Каз өмәләре”  бәйрәменең тарихы турында өйрәнү, дәфтәргә язу.

**Эш кәгазьләре**  Дәфтәрләрдә тәрҗемәи хәл, ышаныч кәгазе язырга өйрәнү. Мәктәптә уздырылачак берәр чара турында белдерү  язу.Эш кәгазьләре үрнәкләре белән танышу.

**Исемнәр.** Кешегә куела торган исемнәр белән танышу. Борынгы һәм хәзерге исемнәрнең куелу тарихын өйрәнү.

Укучылар үзләренең исемнәренең нәрсә аңлатулары турында дәфтәрләргә язалар**.**Укучылар түгәрәктә проект язуның серләренә төшенәләр. “Минем исемем” дигән проект әзерлиләр.

**Кабатлау.**Актлар залында өйрәнгән эшләр буенча  кичә уздыру.Еллык эшләгән эшләргә йомгак ясау.

Бүлекләр

| № | Өйрәнеләчәк бүлек | Сәгать саны |
|---|---|---|
| 1 | Түгәрәк  курсының эчтәлеге | 1 |
| 2 | Күренекле галимнәр | 2 |
| 3 | Татар һәм рус телләрен чагыштырып өйрәнү | 2 |
| 4 | Интонация | 1 |

| | | |
|---|---|---|
| 5 | Фонетика | 3 |
| 6 | Графика | 4 |
| 7 | Лексика | 9 |
| 8 | Җөмлә | 8 |
| 9 | Тел турында мәкальләр һәм әйтемнәр | 2 |
| 10 | Татар халык авыз иҗаты | 8 |
| 11 | Казан- башкалам | 3 |
| 12 | Татар халык ашлары | 2 |
| 13 | Тел дигән дәрья бар | 5 |
| 14 | Милли бәйрәмнәр | 4 |
| 15 | Эш кәгазьләре | 6 |
| 16 | Исемнәр | 6 |
| 17 | Кабатлау | 4 |
| | Барлыгы | 70 |

Пронумеровано
прошнуровано
скреплено
печатью и подписью директора
6( шесть) листов

Директор школы И.М.Ханафеев